**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс (85552) 3-44-14,E-mail:aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_____________ ______

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе күләмен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карары нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Актаныш муниципаль районында 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 2019 елның 1 февраленнән билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. 2019 елның 1 февраленнән «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 гыйнварындагы ПР-10 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Л.Р.Сираевага йөкләргә.

Җитәкче И.Ш.Бариев

Актанышыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карарына «23» 01.2019 № ___
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында
2019 елның 01 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән
хезмәтләр исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | |
| 2. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1400 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен зиратка алып килү | 750 |
| 4. Кабер казу һәм күмү | 3796,47 |
| Барлыгы | 5946,47 |

Актанышыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карарына «23» 01.2019 № _
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында 2019 елның 02 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Кәфенләү | зоо |
| 3. Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны китереп бирү | 1400 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден зиратка илтү | 750 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү ) | 3496,47 |
| Барлыгы | 5946,47 |